# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
# ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
# МӘЛӘКӘС АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

## КАРАР

« 03» апрель 2025 ел Мәләкәс авылы №10

Хайваннарны хуҗаларыннан башка кайтару тыелган урыннарны билгеләү һәм хайваннарны хуҗаларыннан башка элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле затлар исемлеген билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы, «Хайваннар белән җаваплы мөгамәлә турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендә 498-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставына таянып, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты

## КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә хайваннарны хуҗалардан башка кайтару тыелган түбәндәге урыннарны билгеләргә:

- балалар уен һәм спорт мәйданчыклары, спортның актив төрләре белән шөгыльләнү өчен спорт мәйданчыклары, ачык һавада спорт уеннары өчен билгеләнгән мәйданчыклар, бассейн территориясе;
- иҗтимагый территорияләр (парк территориясе, массакүләм ял итү урыннары);
- мәгариф оешмалары һәм сәламәтлек саклау оешмалары территорияләре, күрсәтелгән оешмаларның янәшә территорияләре;
- мәдәният һәм сәнгать объектларының янәшә территорияләре;
- җәмәгать туклануы оешмаларының, сәүдә объектларының янәшә территорияләре;
- күпфатирлы йортларның янәшә территорияләре, аларда урнашкан, мондый йортларга хезмәт күрсәтү һәм эксплуатацияләү өчен билгеләнгән объектлар һәм бу

территорияләрне төзекләндерү элементлары, шул исәптән парковкалар (парковка урыннары), тротуарлар һәм автомобиль юллары белән, күпфатирлы йортларның янәшә территорияләренә керүне тәэмин итүче автомобиль юлларын да кертеп;

- зиратлар һәм мемориаль зоналар.

2. Хайваннарны хуҗаларыннан башка элекке яшәү урыннарына хуҗаларыннан башка кайтару турында карар кабул итүгә вәкаләтле зат итеп Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мәләкәс авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесен билгеләргә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Мәләкәс авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән үз көченә керә.

5.Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Мәләкәс авыл җирлеге
Башкарма комитеты Җитәкчесе — Р.В.Иванов